**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7884**
**28.12.2018**

Башкарма комитетның «2018-2019 елларның кышкы чорында вакытлыча кар өю урыннары турында» 2018 елның 23 ноябрендәге 6985 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Яр Чаллы шәһәренең «Автомобиль юллары предприятиесе» муниципаль унитар предприятиесенең 2018-2019 елларның кышкы чорында вакытлыча кар өю өчен өстәмә урыннар бирү турындагы мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә, Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең 190 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2018-2019 елларның кышкы чорында вакытлыча кар өю урыннары турында» 2018 елның 23 ноябрендәге 6985 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктны түбәндәге эчтәлектәге дүртенче, бишенче абзацлар белән тулыландырырга:

«- Техническая урамы буенча мәйданы 22,75 га булган территориядә (кадастр номеры 16:52:100101:117);

- Техническая урамы буенча мәйданы 2,65 га булган территориядә (кадастр номеры 16:52:100101:8).»;


2) кушымтаны әлеге карарга кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ә. Кыямовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Приложение к
постановлению
Исполнительного комитета
от "__" _________ 20__ г. №___

# Схема расположения мест временного складирования снега в зимний период 2018-2019 гг.




Условные обозначения:

1 улица Карьерная площадью 10 га (карьер КСМ)

2 вдоль проезда Тозелеш площадью 2,5 га

3 по ул. Техническая площадью 22,75 га (кадастровый номер 16:52:100101:117)

4 по ул. Техническая площадью 2,65 га (кадастровый номер 16:52:100101:8)

Руководитель Аппарата
Исполнительного комитета ________________ Г.К. Ахметова